ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**КАРАР**

“20” март 2023 ел　　　　Калмия авылы　　　　№4

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Башкарма комитетының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре турында» 2013 елның 10 гыйнварындагы 1 номерлы Калмия авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 январендагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Тукай районы прокуратурасының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренә 2023 елның 13 мартындагы 02-08-02 номерлы протесты нигезендә һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлеген оештыруны тәэмин итү максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Башкарма комитетының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре турында» 2013 елның 10 гыйнварындагы 1 номерлы Калмия авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Калмия авыл җирлеге Башкарма комитеты хезмәткәрләренә ике ял көне (шимбә, якшәмбе) белән биш көнлек эш атнасы билгеләнә. Хатын-кызлар өчен нормаль эш вакыты озынлыгы – атнага 36 сәгать.”

1.2. 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6.3. Эшнең башлану һәм тәмамлану, ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты түбәндәгечә билгеләнә:

Дүшәнбе:
эш башлана - 8.00;
тәнәфес - 12.00 - 13.00;
эш тәмамлана – 17.00.
сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга:
эш башлана - 8.00;
тәнәфес - 12.00 - 13.00;
эш тәмамлана – 16.00»

1.3. 8.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Хезмәт хакы һәр ярты айдан да сирәгрәк түләнми, хезмәт хакын бирү һәм башка исәп-хисапларны башкару сроклары: агымдагы айның беренче яртысы өчен хезмәт хакы – агымдагы айның 20 числосы; соңгы түләүләр – ул исәпләнгән чор тәмамланганнан соң 5 числода.”

2. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Калмия авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе　　　　Р.Ә.Гарипов